**Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа-Иглай авыл җирлеге Тукай поселогы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**
**КАРАР**

«23» ноябрь 2023 ел №5

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2023 елның 23 ноябрендә узган: «Яңа Иглай авыл җирлеге Тукай торак пункты территориясендә яшәүче һәр балигъ булган кешедән, 1 гр инвалидларыннан тыш, балачактан инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, СВОда катнашучылардан кала 2024 елда 2000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- су белән тәэмин итү системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, лицензияләү, төзү һәм ремонтлау, су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм эчәр су белән тәэмин итү максатыннан халыкка су бирүне тәэмин итүгә;
- Тукай п. чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту;
- Тукай п. территориясен төзекләндерү һәм карап тоту өчен товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу » мәсьәләсе буенча гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

җыенда катнашучы сайлау хокукына ия булган гражданнар исемлегенә 35 кеше кертелгән, җыенда тавыш бирүдә 21 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 20 кеше тавыш бирде;

«ЮК» позициясе өчен җыенның 1 катнашучысы тавыш бирде.

На основании изложенного, сход граждан решил:

1. Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа-Иглай авыл җирлеге Тукай торак пунктында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

Яңа Иглай авыл җирлеге Тукай торак пункты территориясендә яшәүче һәр балигъ булган кешедән, 1 гр инвалидларыннан тыш, балачактан инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, СВОда катнашучылардан кала 2024 елда 2000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- су белән тәэмин итү системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, лицензияләү, төзү һәм ремонтлау, су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм эчәр су белән тәэмин итү максатыннан халыкка су бирүне тәэмин итүгә;

- Тукай п. чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту;

- Тукай п. территориясен төзекләндерү һәм карап тоту өчен товарлар (эшләр, хезмәтләр) сатып алу . мәсьәләсе буенча кабул ителгән карарны танырга.

2. Халык җыены нәтиҗәләрен «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда, Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Яңа Иглай авыл җирлеге мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Яңа Иглай авыл җирлеге тарафыннан кабул ителгән әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә

Халык җыенында рәислек итүче: И.Х. Хәнәфиев

Яңа Иглай авыл җирлеге башлыгы
вазыйфаларын башкаручы И.Х. Хәнәфиев